ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 4 (I өлеш); 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 94 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяның 10 пунктында «чикләү, вакытлыча чикләү яки туктату» сүзләрен «вакытлыча чикләү яисә вакытлыча туктату» сүзләренә алмаштырырга;

2) 12 статьяның 6 пунктында «, капиталь ремонтлауга» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 13 статьяның 1 пунктында «яисә капиталь ремонтлауга» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 25 статьяда:
а) 4 өлештә «хосусый» сүзен төшереп калдырырга;
б) $4^1$ өлештә «хосусый» сүзен төшереп калдырырга;

5) 26 статьяның 3 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:
«$1^1$) авыл җирлеге территориясендә урнашкан хосусый автомобиль юлларына карата – авыл җирлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан;»;

б) 2 пунктта «җирлекнең» сүзен «шәһәр җирлегенең» сүзләренә алмаштырырга, «ашыру җирлек» сүзләрен «ашыру шәһәр җирлеге» сүзләренә алмаштырырга;

б) 28 статьяда:

а) 1 өлештә «хәрби техника, транспорт чаралары» сүзләреннән соң «, федераль иминлек хезмәте органнары транспорт чаралары, шулай ук махсус ут һәм тавыш сигналлары бирү өчен җайланмалар куелган һәм гадәттән тыш хәлләргә оператив чара күрү, аларны кисәтү һәм алардан килгән зыянны бетерү максатларында янгыннан саклау, һәлакәттән коткару хезмәтләре, һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган махсус транспорт чаралары» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешнең беренче җөмләсендә «тәэмин итү өлкәсендәге» сүзләреннән соң «махсус» сүзен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 6 пунктының «а» пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 6 пунктының «а» пунктчасы 2021 елның 30 декабреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2021 ел, 04 октябрь
№ 73-ТРЗ